КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 февраль г.Казань № 114

Казан шәһәре, Максим Горький урамы, 17 йорт адресы буенча бина фасадына мемориаль такта урнаштыру турында

Күренекле татар опера җырчысы, педагог, ТАССРның атказанган артисты, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Мөнирә Закир кызы Булатова истәлеген мәңгеләштерү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, «Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт академия опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесенең һәм «Россия Федерациясе театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Мөнирә Закир кызы Булатовага, ул 1940 – 2011 елларда яшәгән Казан шәһәре, Максим Горький урамы, 17 йорт адресы буенча бина фасадына татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта урнаштыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

«Бу йортта 1940 – 2011 елларда
күренекле татар опера җырчысы,
педагог һәм җәмәгать эшлеклесе,
РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты
Мөнирә Булатова яшәде
___________

В этом доме в 1940 – 2011 гг. жила
выдающаяся татарская оперная певица,
педагог и общественный деятель,
народная артистка РСФСР и ТАССР
Мунира Булатова».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин